ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**“ 26 ” мая 2026 ел** **№ 428**

**“2026 - 2028 елларга Арча муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” программасын раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган “Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән расланган “Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программаларының аерым чараларын гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү” дәүләт программасын раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Кушымта нигезендә “2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеген программаның заказчы – координаторы итеп билгеләргә.

3. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы” МКУга ел саен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының чираттагы финанс елына бюджетын формалаштырганда Программа чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан әлеге максатларга юнәлдерелә торган акчаларның мөмкинлекләрен исәпкә алып һәм чикләрендә карауны тәкъдим итәргә.

4. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

“2019 – 2020 елларга Арча муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасын раслау турында” 2018 елның 27 ноябрендәге 1197 номерлы карары;

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “2019-2020 елларга Арча муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасын раслау турында” 2018 елның 27 ноябрендәге 1197 номерлы карары белән расланган “2019-2020 елларга Арча муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” программасына үзгәрешләр кертү турында” 2019 елның 16 декабрендәге 1103 номерлы карары.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштырып халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л. И. Абдуллин